КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2024 ел, 16 июль

г.Казань

№ 571

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 5 июль, 638 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларының төгәлләнмәгән төзелешенә сарыф ителгән чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларының төгәлләнмәгән төзелешенә сарыф ителгән чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2022 ел, 5 июль, 638 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 10 октябрь, 1288 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларының төгәлләнмәгән төзелешенә

сарыф ителгән чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Алга таба чыгымнарны гамәлгә ашыру, тәгәлләнмәгән төзелеш объектын төзү мөмкинлеге булмауның һәм (яки) максатка ярашлы булмауның нигезләве бирелгән аңлатма материаллар, шулай ук кабул ителә торган карарның финанс-икътисадый нигезләве белән исәптән чыгару турында карар проекты Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан әзерләнә һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче вәкаләтләре гамәлгә ашырылмаган очракта), Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (транспорт инфраструктурасы өлкәсендә тәгәлләнмәгән төзелеш объектлары һәм ясалган чыгымнар буенча), Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты (территориясендә тәгәлләнмәгән төзелеш объекты урнашкан) (алга таба – Башкарма комитет) килештерүгә җибәрелә. Исәптән чыгару турында карар проектын килештерү срогы карар проекты кергән көннән 14 календарь көннән артмаска тиеш, әлеге срок эчендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм Башкарма комитетның җаваплары булмаган очракта, исәптән чыгару турында карар проекты килештерелгән дип санала.»;

11 пунктта:

беренче абзацта «Бу Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләреннән соң «, Башкарма комитет» сүзләрен өстәргә;

«в» пунктчасында «бу Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының» сүзләреннән соң «, Башкарма комитетның» сүзләрен өстәргә;

12 пунктта «Бу Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләреннән соң «, Башкарма комитет» сүзләрен өстәргә;

13 пунктта «Бу Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләреннән соң «, Башкарма комитет» сүзләрен өстәргә;

14 пунктта «Бу Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының берсе» сүзләреннән соң «, Башкарма комитет» сүзләрен өстәргә;

16 пунктта «Бу Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының берсе» сүзләреннән соң «, Башкарма комитет» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин